**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИ-ПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИ-ТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ ПР-227 22.10.2024 № _____

**«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә әзерләү турында»**

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы нигезләмәне раслау турында» 1999 елның 31 декабрендәге 1441 номерлы карары нигезендә, «Тормыш иминлеге нигезләре» курсын укыту сыйфатын яхшырту һәм укучыларны хәрби-патриотик тәрбияләүне камилләштерү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар планы (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә әзерләүне тикшерү комиссиясе составы (2 нче кушымта).

1.3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә мәҗбүри әзерләү буенча штаттан тыш методик совет составы (3 нче кушымта).

1.4. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә мәҗбүри әзерләү буенча штаттан тыш методик советның эш планы (4 нче кушымта).

1.5. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының урта (тулы) гомуми һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларында 2024-2025 уку елында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү торышын тикшерү планы (5 нче кушымта).

1.6. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә әзерләү графигы (6 нчы кушымта).

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисенә расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2025 уку елында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында» 2024 елның 05 сентябрендәге ПР-158 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.А.Ильясов

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
_________ 2024 ел, №___ карарына
1 нче кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ГРАЖДАННАРЫН 2024-2025 УКУ ЕЛЫНДА ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘ МӘҖБҮРИ ӘЗЕРЛӘҮ БУЕНЧА ШТАТТАН ТЫШ МЕТОДИК СОВЕТНЫҢ ЭШ ПЛАНЫ**

| № т/б | Чаралар атамасы | Җаваплы башка-ручы | Башкару ва-кыты |
|---|---|---|---|
| | **I. ОЕШТЫРУ ЧАРАЛАРЫ** | | |
| 1 | Төп планлаштыру документларын эшләү, шул исәптән:<br>а) Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә әзерләү турында проект-карар;<br>б) 2024-2025 уку елында хәрби хезмәт нигезләре буенча уку-укыту җыеннарын оештыру һәм үт-кәрү турында карар проекты. | мәгариф идарәсе башлыгы, Актаныш муници-паль районы хәр-би комиссары | уку елы дәвамында |
| 2 | Учреждение, предприятие, оешма җитәк-челәренә Татарстан Республикасы Актаныш му-ниципаль районы Башкарма комитеты җитәкче-сенең карарын һәм Татарстан Республикасы Ак-таныш муниципаль районы гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү буенча төп чаралар планын җиткерергә. | Башкарма комитет-ның гомуми бүлеге, Актаныш районы хәрби комиссары | 25.09.2024 кадәр |
| | **II. Гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләүне кадрлар һәм укыту-методик тәэмин итү** | | |
| 1 | Белем бирү оешмаларын «Тормыш иминлеге ни-гезләре» һәм «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы буенча укытучылар белән комплектлау. | Актаныш районы хәрби комиссары, мәгариф идарәсе башлыгы | даими |
| 2 | Белем бирү оешмаларына «Тормыш иминлеге нигезләре» һәм «Хәрби хезмәт нигезләре» кур-сларын укыту өчен укыту-методик һәм күрсәтмә әсбаплар белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү. | мәгариф идарәсе башлыгы | |
| | **III. ГРАЖДАННАРНЫ ХӘРБИ ХЕЗМӘТ НИГЕЗЛӘРЕ БУЕНЧА ӘЗЕРЛӘҮ** | | |
| 1 | Гражданнарны «Тормыш иминлеге нигезләре» һәм «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы буенча укытуны оештыру | гомуми белем бирү оешмалары, урта һөнәри белем бирү оешмалары җитәк-челәре<br>. | уку елы дәвамында |
| 2 | Гомуми белем бирү оешмаларының 10 сыйныф укучылары һәм урта һөнәри белем бирү оешма-ларының чыгарылыш алды курслары белән биш | Башкарма комитет, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм | май - июнь 2025 ел |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | көнлек уку җыеннары үткәрү. | буенча бүлек баш-<br>лыгы;<br>мәгариф идарәсе<br>башлыгы,,<br>Актаныш районы<br>хәрби комиссары | |
| 3 | Хәрби хезмәт нигезләре буенча слетлар, ярышлар, конкурслар, олимпиадалар үткәрү | белем бирү учре-<br>ждениеләре, урта<br>һөнәри белем бирү<br>учреждениеләре<br>җитәкчеләре | уку елы<br>дәвамында |
| 4 | Гомуми белем бирү оешмалары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары арасында «Тормыш иминлеге нигезләре» һәм «Хәрби хезмәт нигез-ләре» курсы буенча иң яхшы укытучыга һәм хәр-би хезмәт һәм хәрби - патриотик эш нигезләре буенча иң яхшы укыту матди базасына смотр-конкурс үткәрү. | мәгариф идарәсе<br>башлыгы,<br>Актаныш районы<br>хәрби комиссары | уку елы<br>дәвамында |
| **IV. ГРАЖДАННАРНЫ ХӘРБИ-ПАТРИОТИК ТӘРБИЯЛӘҮ** | | | |
| 1 | Белем бирү оешмаларында Ватан тарихына багышланган дәресләр, хәрби-патриотик юнәлештәге класстан тыш чаралар үткәрү | яшьләр эшләре,<br>спорт һәм туризм<br>буенча бүлек баш-<br>лыгы;<br>мәгариф идарәсе<br>башлыгы | уку елы<br>дәвамында |
| 2 | Ватанны саклаучылар көненә багышланган обо-рона - массакүләм һәм спорт эше буенча чара-лар үткәрү | башкарма комитет,<br>мәгариф идарәсе<br>башлыгы,<br>Актаныш районы<br>хәрби комиссары | уку елы<br>дәвамында |
| 3 | «Хәрби хезмәткә чакырылу көне” социаль-патри-отик акциясен үткәрү | мәгариф идарәсе<br>башлыгы,<br>Актаныш районы<br>хәрби комиссары | план буенча |
| 4 | Хәрби комиссариат (Түбән Кама шәһәре һәм Та-тарстан Республикасы Актаныш муниципаль рай-оны, ) вәкилләре, шулай ук Бөек Ватан сугышы ветераннары белән балалар һәм яшьләр очра-шулары үткәрү | мәгариф идарәсе<br>башлыгы<br>Актаныш районы<br>хәрби комиссары | уку елы<br>дәвамында |
| | **V. МЕДИЦИНА ТИКШЕРЕНҮЕ** | | |
| 1 | Табиблар - медицина тикшерүендә катнашучы белгечләр белән инструктор-методик җыеннар үткәрү | «Актаныш районы<br>үзәк хастаханәсе»<br>ДАССУ баш таби-<br>бы,<br>табиб-терапевт,<br>Актаныш районы<br>хәрби комиссариа-<br>ты | 25.09.2024<br>кадәр,<br>24.03.2025<br>кадәр |
| 2 | Хәрби исәпкә куелганда гражданнарны медицина тикшерүен оештыру һәм уздыру | «Актаныш районы<br>үзәк хастаханәсе»<br>ДАССУ баш таби-<br>бы<br>табиб-терапевт | 01.04.2025<br>кадәр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Актаныш хәрби комиссариаты | |
| 3 | Гражданнарны хәрби хезмәткә чакырганга кадәр, аларны үз вакытында контрольдә тотуны гамәлгә ашырып, гражданнарны хәрби исәпкә кую чорында тулы күләмдә медицина тикшерүе үткәрү. | "Актаныш РҮХ" ДАССУ баш табибы | 01.10-29.12.2024 , 01.04.-15.07.2025 |
| **VI. ДӘВАЛАУ-САВЫКТЫРУ ЭШЕ** | | | |
| 1 | Беренчел хәрби исәпкә куелу нәтиҗәләре буенча 1,2,3 номерлы исемлеккә кертелгән, шулай ук хәрби хезмәткә чакырылу йомгаклары буенча вакытлыча яраксыз дип танылган 2007 елгы гражданнар белән дәвалау-савыктыру чараларын үткәрү. | «Актаныш районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы табиб-терапевт Актаныш районы хәрби комиссариаты | |
| | Беренчел хәрби исәпкә куелганчы 15-16 яшьлек (2008-2009 елгы) гражданнарга профилактик медицина тикшерүе үткәрү. | "Актаныш РҮХ" ДАССУ баш табибы | 01.04-25.05.2025 |
| 2 | Көндезге уку формасындагы югары һәм урта белем бирү оешмалары студент-яшьләрен хәрби хезмәткә әзерләү максатында профилактик медицина тикшерүе нәтиҗәләре буенча дәвалау – савыктыру чаралары үткәрү. | «Актаныш районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы табиб-терапевт Актаныш районы хәрби комиссариаты | 01.10 - 29.12.2024, 01.04 - 15.07.2025 |
| 3 | Хәрби хезмәткә чакырылганга кадәр гражданнар белән дәвалау-савыктыру чараларын уздыруның нәтиҗәлелеген тикшереп тору. | «Актаныш районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы табиб-терапевт Актаныш районы хәрби комиссариаты | 29.12.2024 кадәр 15.07.2025 кадәр |
| | **VII. ГРАЖДАННАРНЫ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘ ИРЕКЛЕ ӘЗЕРЛӘҮ** | | |
| 1 | Россия Федерациясе Оборона министрлыгының югары хәрби белем бирү оешмаларына керү өчен кандидатларны сайлап алуны оештыру һәм җибәрү. | Башкарма комитет, Актаныш муниципаль районы хәрби комиссары | 01.02 – 30.04.2025 |
| 2 | Кандидатларны җыю һәм аларны суворов хәрби училищеларына, хәрби-музыка училищеларына, кадет корпусларына укырга җибәрү. | Башкарма комитет, Актаныш районы хәрби комиссары | 01.02-25.07.2025 |
| 3 | Клублар, секцияләр, спортның хәрби-гамәли төрләре буенча түгәрәкләр эшен оештыру һәм аларның слетларын үткәрү. | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы, мәгариф идарәсе | уку елы дәвамында |

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
_________ 2024 ел, №___ карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә әзерләүне тикшерү комиссиясе составы**

Комиссия рәисе

| | |
|---|---|
| Ильясов<br>Рөстәм Алмаз улы | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Хәев А.Р. | "Актаныш район үзәк хастаханәсе" ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Шакирова Р. М. | «Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы (килешү буенча); |
| Минһаҗев М.Р. | ТР Актаныш районы буенча Россия ЭЭМ идарәсе башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы, подполковник (килешү буенча); |
| Әхмәтҗанов Л. С. | Актаныш районы хәрби комиссары (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
_________ 2024 ел, №___ карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә мәҗбүри әзерләү буенча штаттан тыш методик совет составы**

| | |
|---|---|
| Совет рәисе<br>Ильясов<br>Рөстәм Алмаз улы | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Совет әгъзалары: | |
| | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы; |
| | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләренең ТИН оештыручы-укытучыларның методик берләшмәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе методисты; |
| | «Актаныш технология техникумы» дәүләт аграр һөнәри белем бирү учреждениесенең хәрби-исәпкә алу инспекторы (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
_______ 2024 ел, №___ карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә мәҗбүри әзерләү буенча штаттан тыш методик советның эш планы**

| № т/б | Чаралар атамасы | Үтәү вакыты | Чараны уздыру өчен җаваплы оештыручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **I. ОЕШТЫРУ ЧАРАЛАРЫ** | | | |
| 1. | Утырышларда гражданнарны 2022-2023 уку елында хәрби хезмәткә әзерләү йомгакларын һәм яңа 2023-2024 уку елына бурычларны карарга. | сентябрь 2024 ел | мәгариф идарәсе башлыгы,<br>Актаныш районы хәрби комиссары<br>методик совет әгъзалары |
| 2. | Гражданнарны белем бирү оешмаларында хәрби хезмәткә әзерләүне алга таба яхшырту һәм укыту-матди базаны камилләштерү буенча чаралар күрергә. | сентябрь 2024 ел | Методик совет әгъзалары |
| 3. | Яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү буенча җитәкче документларны өйрәнергә. "Тормыш иминлеге нигезләре" һәм "Хәрби хезмәт нигезләре" курсы программасы белән танышырга. Вазыйфаларны бүлү. | сентябрь 2024 ел | Методик совет әгъзалары |
| 4. | «Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре» һәм «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы буенча укытучылар белән укыту-методик җыеннар уздыруга әзерләнергә һәм шөгыль җитәкчеләренә методик ярдәм күрсәтергә. | сентябрь 2024 ел | Методик совет әгъзалары |
| 5. | «Тормыш иминлеге нигезләре» һәм «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы буенча укытучылар белән укыту-методик җыеннар үткәрергә. | сентябрь 2024 ел | Актаныш районы хәрби комиссары |
| 6. | Эшкә йомгак ясау, фикер алышына торган эшләр буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм шөгыльләр үткәрүдә ярдәм күрсәтү буенча советның айлык утырышларын уздырырга. | чиреккә бер тапкыр | Методик совет әгъзалары |
| 7. | Ай саен бер көнлек шөгыльләр үткәрүгә әзерлекне тикшерергә һәм шөгыль җитәкчеләренә методик ярдәм күрсәтергә. | айга бер тапкыр | Методик совет әгъзалары |
| 8. | Хәрби-гамәли юнәлештәге ярышларда массакүләм катнашуны арттыру буенча чаралар күрергә. Белем бирү оешмасында «Тормыш иминлеге нигезләре» һәм «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы буенча укытучыларга методик ярдәм күрсәтү һәм төрле темалар буенча ачык | уку елы дәвамында | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча бүлек башлыгы; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | дәресләр үткәрү. | | |
| **II. УКУЧЫЛАРГА ХӘРБИ-ПАТРИОТИК ТӘРБИЯ БИРҮ** | | | |
| 1. | Россия Федерациясе Оборона министрлыгының югары һәм урта һөнәри белем бирү хәрби белем бирү оешмаларына кандидатлар сайлау буенча уку йортларын тәмамлаучылар арасында эш алып барырга. | уку елы дәвамында | мәгариф идарәсе башлыгы,<br>Актаныш районы хәрби комиссары |
| 2. | Гражданнарны беренчел хәрби исәпкә кую эшендә ярдәм күрсәтергә. | сентябрь 2024 ел - март 2025 ел | Методик совет әгъзалары |
| 3. | Үткәрергә:<br>- җыр һәм строй смотры;<br>- хәрби-спорт эстафетасы;<br>- хәрби-патриотик уен «Аҗаган»;<br>- тантаналы парад. | уку елы дәвамында | яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча бүлек башлыгы;<br>Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары<br>Мәгариф идарәсе башлыгы<br>. |
| 4. | Гомуми белем бирү оешмаларының 10 сыйныфында һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларының чыгарылыш алды курсларында укучылар белән план, программа эшләргә һәм бишкөнлек уку җыеннары үткәрергә. | май 2025 ел | мәгариф идарәсе башлыгы,<br>Актаныш районы хәрби комиссары |
| 5. | Штаттан тыш методик советның узган елгы эшенә йомгак ясарга. | май 2025 ел | Методик совет әгъзалары |
| 6. | Татарстан Республикасы хәрби комиссариаты куйган бурычларны исәпкә алып, яңа уку елына Советның эш планын эшләргә. | июль 2025 ел | Методик совет әгъзалары |

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты
_________ 2024 ел, №___ карарына
5 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының урта (тулы) гомуми һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларында гражданнарны 2024-2025 уку елында хәрби хезмәткә әзерләү торышын тикшерү планы**

«Тормыш иминлеге нигезләре» (ОБЖ) һәм «Хәрби хезмәт нигезләре» (ОВС) курсы буенча белем бирү оешмаларын түбәндәге юнәлешләр буенча тикшерергә:

1. Кадрлар мәсьәләсе:

1.1 «Тормыш иминлеге нигезләре» һәм «Хәрби хезмәт нигезләре» курсы буенча укытучының методик күнекмәләре, дәрес үткәрүнең сыйфаты.

1.2 "ТИН" һәм "ХХН" курсы буенча укытучыны дәрескә әзерләү, конспект, техник тәэмин ителеш.

1.3 Норматив документларны, вазыйфаи бурычларны белү.

2. Укыту эше:

2.1 Укыту планы нигезендә дәүләт программасы таләпләрен үтәү; «ТИН» һәм «ХХН» предметы буенча белем бирү оешмасының документлары (боерыклар, планнар, сыйныф журналларының торышы).

2.2 «ТИН» һәм «ХХН» курсын укытуның торышы, укучыларның белем, күнекмәләр сыйфаты, аларның уку материалын үзләштерүе. «ТИН» һәм «ХХН» буенча практик дәресләр үткәргәндә куркынычсызлык техникасын үтәү.

2.3 Эчке контроль:

«ТИН» һәм «ХХН» курсы буенча белем бирү оешмасы директоры, укыту эшләре буенча директор урынбасары, методик эшләр буенча директор урынбасары, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары тарафыннан тикшерелгән дәресләр саны, тикшерелгән дәресләрнең һәм сыйныфтан тыш чараларның анализы һәм нәтиҗәләре булу. Педагогик советта, киңәшмәләрдә каралган мәсьәләләр. Беркетмәләр булу. Кабул ителгән карарларны үтәү барышы.

3. Белем бирү оешмаларының укыту-матди базасы (УМБ) һәм техник базасы:

3.1 "ТИН" курсы программасы таләпләренә ярашлы рәвештә, УМБ элементларының торышы һәм булуы. ТИН кабинетының булуы һәм җиһазлары. Каршы килү полосасының хәле. Чыдамлылыкка актның булуы.

3.2 Техник тәэмин ителеш. Хәрби-патриотик темаларга фәнни-популяр һәм документаль диафильмнар, кинофильмнар һәм видеофильмнар күрсәтү планы.

3.3 Табельле мөлкәтнең, сугыш кирәк-яракларының, уку коралының торышы һәм булуы. Исәпләү кенәгәләре, тикшерү актлары булу.

3.4 Корал саклау бүлмәсе булу.

3.5 Тир.

3.6 Тактика һәм гражданнар оборонасы буенча өйрәнү шәһәрчеге.

3.7 Атыш алымнарын һәм кагыйдәләрен практик өйрәнү мәйданчыгы.

3.8 Коралны чистарту һәм майлау өчен урын.

3.9 Спорт залы.

3.10 Гимнастик шәһәрчек.

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты
_________ 2024 ел, №___ карарына
6 нчы кушымта

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы гражданнарын 2024-2025 уку елында белем бирү оешмаларында хәрби хезмәткә әзерлеген тикшерү графигы

| № т/б | Оешманың исеме | Тикшерү вакыты | искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1. | «1 нче санлы Актаныш урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ | сентябрь, март | |
| 2. А | «Аерым фәннәрне тирәнтен үзләштерүле 2 нче санлы Актаныш урта мәктәбе» МБББУ | сентябрь, март | |
| 3. | «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» ДАББУ | сентябрь, март | |
| 4. | "Киров урта гомуми белем бирү мәктәбе" МБББУ | сентябрь, март | |
| 5. | «Пучы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ | сентябрь, март | |
| 6. | «Сәфәр урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ | сентябрь, март | |
| 7. | "Татар Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБББУ | сентябрь, март | |
| 8. | «Актаныш технология техникумы» ДАҺББУ | сентябрь, март | |